КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 7 февраль г.Казань № 64

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планын раслау турында» 2016 ел, 28 декабрь, 1020 нче карары белән расланган Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планын раслау турында» 2016 ел, 28 декабрь, 1020 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 май, 289 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның 100 еллыгын әзерләү һәм бәйрәм итү буенча чаралар планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

53 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «53. | Татарстан Республикасы рәсми порталында бердәм челтәр мәгълүмат ресурсын (100.tatarstan.ru) булдыру һәм аңа техник ярдәм күрсәтү | 2017 – 2020 еллар | Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы»; |

түбәндәге эчтәлекле 53.1 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «53.1. | Татарстан Республикасы рәсми порталында бердәм челтәр мәгълүмат ресурсына (100.tatarstan.ru) мәгълүмати ярдәм күрсәтү һәм аны тулыландыру | 2017 – 2020 еллар | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (килешү буенча), Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин